**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 маендагы 1724 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 23 июнендәге 1881 номерлы «Шәһәрнең торак массивлары территориясендә оешкан һәм гамәлдә булган территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 23 июнендәге 1881 номерлы «Шәһәрнең торак массивлары территориясендә оешкан һәм гамәлдә булган территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарының кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Субсидияләр әлеге тәртип нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет исемлегендәге бюджет чыгымнары классификациясенең тиешле кодлары буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы булып торган Казан шәһәре Башкарма комитетының тиешле район администрациясе (алга таба – Вәкаләтле орган) өчен агымдагы финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә

әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә»;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Субсидия турында мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы (алга таба – «Интернет» челтәре, бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләрен бюджет акчаларын баш бүлүчегә җиткергән көннән соң килә торган 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла»;

1.3. 19 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«19. Вәкаләтле орган, сайлап алуны уздыру турында белдерү белән билгеләнгән гаризаларны ачу көненнән соң килә торган өч эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуда катнашу өчен тапшырылган гаризалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган гаризаларны ачу турында беркетмәне имзалый:

а) гаризаның теркәү номеры;

б) гаризаның керү көне һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы атамасы;

г) юридик зат адресы.

1.4. 23 пунктны төшереп калдырырга;

1.5. 24 пунктны төшереп калдырырга;

1.6. 28 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«28. Сайлап алуны тәгәлләү һәм сайлап алу җиңүчесен ачыклау максатыннан сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчесен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аны имзалаган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, – бердәм порталда һәм, сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

Беркетмәгә түбәндәге белешмәләр керә:

- гаризаларны карап тикшерү көне, вакыты һәм урыны;

- гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның

сайлап алу уздыру турындагы игъланның кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- килешү төзелә торган сайлап алу җиңүчесенең исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

Сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, гаризаларны карап тикшерү беркетмәсенең һәм сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсенең беренче версияләре имзаланган көннән алып ун календарь көннән дә соңга калмыйча, әлеге беркетмәләрнең, мондый үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, яңа версияләрен формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

1.7. 36 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«36. Вәкаләтле орган әлеге тәртипнең 35 пунктында күрсәтелгән документларны терки һәм документлар теркәлгән көннән алып биш эш көн эчендә аларны карый һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Субсидия бирү турында карар субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән форма буенча рәсмиләштерелә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**